Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы
КАРАР

01 ноябрь, 2024 ел № 2

Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебаш авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебашторак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 4 апрелендәге 1 номерлы Түбән Өскебашавылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Өскебаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 12 ноябренә 9 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебаш торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 4 апрелендәге 1 номерлы Түбән Өскебашавылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Өскебаш авылы, Советская урамы, йорт 66А клубта уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2024 елның 4 апрелендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы:

-4нче пунктка өстәмә абзац өстәргә:

торак пункт территориясен төзекләндерү (трактор өчен асылма җиһазлар һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторны карап тоту, "Беларус 82.1" тракторы өчен запчастьләр сатып алу, проект-смета документациясен әзерләү һәм шартнамә буенча түләү, технадзор)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге башлыгы: Н.М.Мөхәммәтҗанов